**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№1723**
**19.03.2024**

Башкарма комитетның «2023-2025 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә физик культура һәм спортны үстерү» муниципаль программасы турында» 2022 елның 7 октябрендәге 5362 номерлы Карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, шәһәр Уставының 41 статьясы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы Карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты, Башкарма комитетның «Муниципаль программаларны эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2017 елның 11 сентябрендәге 5326 номерлы Карары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «2023-2025 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә физик культура һәм спортны үстерү» муниципаль программасы турында» 2022 елның 7 октябрендәге 5362 номерлы Карарына (Башкарма комитетның 2023 елның 31 мартындагы 2597 номерлы, 2023 елның 25 июлендәге 6656 номерлы, 2023 елның 1 декабрендәге 11684 номерлы Карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Башкарма комитетның финанс идарәсенә «2023-2025 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә физик культура һәм спортны үстерү» муниципаль программасын тормышка ашыру буенча чараларны финанслауны шәһәр бюджетында «Физик культура» 1101, «Югары казанышлар спорты» 1103 һәм «Массакүләм спорт» 1102 бүлекләре (бүлекчәләре) буенча каралган акчалар хисабына 2 323 041,20 мең сум күләмендә тәэмин итәргә: 2023 ел – 859 890,48 мең сум, 2024 ел – 728 958,95 мең сум, 2025 ел – 734 191,77 мең сум.»;

2) «2023-2025 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә физик культура һәм спортны үстерү» муниципаль программасында:

- 1 бүлектә «Еллар буенча бүлеп, программаны финанслау күләме һәм чыганаклары» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| «Еллар буенча бүлеп, Программаны финанслау күләме һәм чыганаклары | Финанслау чыганаклары (мең сум) | Программаны тормышка ашыру еллары | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | 2023 ел | 2024 ел | 2025 ел | Тормышка ашыру чорында барлыгы |
| | Муниципаль бюджет | 754 669,31 | 724 401,54 | 734 191,77 | 2 213 262,62 |
| | Федераль бюджет | 58 424,75 | | - | 58 424,75 |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | Республика бюджеты | 46 796,42 | 4 557,41 | - | 51 353,83 |
| | Барлыгы | 859 890,48 | 728 958,95 | 734 191,77 | 2 323 041,20»; |

- 6 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6 бүлек. Программаны ресурслар белән тәэмин итү

Программа чараларын тормышка ашыру өчен 2 323 041,20 мең сум күләмендә муниципаль бюджет акчаларыннан файдалану күздә тотыла: 2023 ел – 859 890,48 мең сум, 2024 ел – 728 958,95 мең сум, 2025 ел – 734 191,77 мең сум.»;

- 8 бүлекне кушымтада каралганча яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы С.Р. Мулюковага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2024 елның 19 мартындагы
1723 номерлы карарына
кушымта

8 бүлек. «2023-2025 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә физик культура һәм спортны үстерү» программасының максатлары, бурычлары, нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары һәм Программа чаралары буенча финанслау

| № т/б | Төп чараларның исеме | Башкаручылар | Төп чараларны үтәү сроклары | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | Индикаторларның зурлыгы | | | | Финанслау чыганакларын күрсәтеп, мең сум | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | 2022 ел | 2023 ел | 2024 ел | 2025 ел | 2023 год | 2024 ел | 2025 ел |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
| Программаның максаты: җәмгыятьнең төрле катлауларын физик культура һәм спорт белән даими шөгыльләнүгә җәлеп итү | | | | | | | | | | | |
| Бурычның исеме: халыкны физик культура һәм спорт белән системалы шөгыльләнүгә җәлеп итү дәрәҗәсен арттыру | | | | | | | | | | | |
| 1. | Физик культура һәм массакүләм спортны үстерү мәсьәләләре буенча муниципаль хокукый актлар эшләү һәм аларны раслау, халыкның төрле яшь төркемнәре арасында физкультура-сәламәтләндерү, комплекслы спорт чаралары үткәрү | Башкарма комитетның физик культура һәм спорт идарәсе | ел саен | Физик культура һәм спорт белән системалы шөгыльләнүче халык өлеше, халыкның гомуми санында, % | 55,9 | 62,2 | 64 | 66 | | | |
| 2. | Сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикле кешеләр һәм инвалидлар арасында шәһәр физкультура-сәламәтләндерү, комплекслы чаралар, фестивальләр, спорт бәйрәмнәре үткәрү | Башкарма комитетның физик культура һәм спорт идарәсе | ел саен | Физик культура һәм спорт белән даими шөгыльләнүче сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикле затлар һәм инвалидлар өлеше, халыкның әлеге категориясенең гомуми санында, % | 20 | 21,5 | 22 | 22,5 | | | |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 3. | Халыкның төрле яшь төркемнәре арасында «Хезмәткә һәм оборонага әзер» (ГТО) Бөтенроссия физкультура-спорт комплексын популярлаштыруга юнәлдерелгән чаралар оештыру һәм үткәрү | Башкарма комитетның физик культура һәм спорт идарәсе | ел саен | «Хезмәткә һәм оборонага әзер» (ГТО) Бөтенроссия физкультура-спорт комплексы нормативларын үтәгән халык өлеше, ГТО нормативларын үтәүдә катнашкан халыкның гомуми санында, % | 37 | 37,5 | 38 | 38,5 | | | |
| 4. | Төрле яшь категорияләре арасында спорт төрләре буенча чемпионатлар, беренчелекләр, кубоклар үткәрү | Башкарма комитетның физик культура һәм спорт идарәсе | ел саен | Спорт төрләре буенча чемпионатлар, беренчелекләр, кубоклар, массакүләм ярышлар саны, берәмлек | 20 | 20 | 20 | 20 | Муниципаль бюджет | | |
| | Төрле яшь категорияләре арасында спорт төрләре буенча массакүләм ярышлар үткәрү | | | | | | | | 1 801,32 | 1 601,60 | 1 518,20 |
| 5. | «Сабан туе» халык бәйрәме кысаларында спорт төрләре буенча ярышлар, милли халык уеннары һәм көч сынашулар үткәрү | Башкарма комитетның физик культура һәм спорт идарәсе | ел саен | «Сабан туе» халык бәйрәме кысаларында ярышлар саны, берәмлек | 27 | 27 | 27 | 27 | Муниципаль бюджет | | |
| | | | | | | | | | 1 000,0 | 1 000,0 | 1 000,0 |
| 6. | Хаким Кубогына спорт төрләре буенча шәһәр чемпионатлары һәм беренчелекләре, «Физик мөмкинлекләре чикле кешеләр арасында Яр Чаллы шәһәре Хакиме Кубогы»на ярышлар үткәрү | Башкарма комитетның физик культура һәм спорт идарәсе | ел саен | Яр Чаллы шәһәре Хакиме Кубогына ярышлар саны, берәмлек | 8 | 21 | 21 | 21 | Муниципаль бюджет | | |
| | | | | | | | | | 200,0 | 200,0 | 200,0 |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Бурычның исеме: югары казанышлар спортын үстерү. Спорт резервын әзерләүнең нәтиҗәле системасын булдыру | | | | | | | | | | | |
| 7. | Шәһәр Хакиме стипендияләре түләү юлы белән физик культура һәм спорт өлкәсендә талантлы укучыларга ярдәм күрсәтү | Башкарма комитетның физик культура һәм спорт идарәсе | ел саен | Хаким стипендиясен алган балалар һәм яшүсмерләр саны, кеше | 10 | 10 | 10 | 10 | Муниципаль бюджет | | |
| | | | | | | | | | 120,0 | 120,0 | 120,0 |
| 8. | Югары һөнәри осталыклары өчен муниципаль физик культура һәм спорт учреждениеләре хезмәткәрләренә шәһәр Хакиме премиясен бирү | Башкарма комитетның физик культура һәм спорт идарәсе | ел саен | Физик культура һәм спорт учреждениеләренең Хаким премиясен алган хезмәткәрләре саны, кеше | 15 | 15 | 15 | 15 | Муниципаль бюджет | | |
| | | | | | | | | | 390,6 | 390,6 | 390,6 |
| 9. | Халыкара һәм Бөтенроссия ярышларында югары спорт казанышлары өчен спортчыларга бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү | Башкарма комитетның физик культура һәм спорт идарәсе | ел саен | Россия, Европа, дөнья чемпионатларында, Олимпия уеннарында, Бөтендөнья Универсиадасында бүләкләр алган җиңүчеләр һәм призерлар саны, кеше | 40 | 11 | 20 | 20 | Муниципаль бюджет | | |
| | | | | | | | | | 596,27 | 1 000,0 | 1 083,40 |
| 10. | Түбәндәге спорт төрләре буенча спорт әзерлеге программасын тормышка ашыру: баскетбол, волейбол, җиңел атлетика, спорт ориентлашуы, дзюдо, каратэ киокусинкай, кикбоксинг, йөзү, синхрон йөзү, нәфис гимнастика, велоспорт, спорт гимнастикасы, теннис, тимераякта узышу спорты, футбол, велоспорт (шоссе), билбаулы көрәш, грек-рим | 16 муниципаль физик культура һәм спорт учреждениесе | ел саен | Югары спорт осталыгы этабында спорт әзерлеге программаларын тормышка ашыру нәтиҗәләре буенча тиешле спорт төре буенча федераль спорт әзерлеге стандарты таләпләрен үтәгән һәм спорт әзерлеге узган затлар өлеше, % | 80 | 80 | 80 | 80 | 749 556,80 | 720 089,34 | 729 879,57 |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | көрәше, армреслинг, көрәш, тхэквондо, күп стильдәге каратэ, батутта сикерү, акробатика юлы, спорт акробатикасы, бокс, авыр атлетика, чаңгы узышлары, бию спорты, ат спорты, спорт туризмы, өстәл теннисы, бадминтон, җилкәнле спорт, фехтование, пауэрлифтинг, алкалы хоккей, тимераякта фигуралы шуу, шахмат | | | Спорт осталыгын камилләштерү этабында спорт әзерлеге узган һәм югары спорт осталыгы этабына кертелгән затлар өлеше, % | 10 | 10 | 10 | 10 | | | |
| | | | | Тренировкалар этабында (спорт белгечлеге этабы) спорт әзерлеге узган һәм спорт осталыгын камилләштерүнең барлык этабына кертелгән затлар өлеше, % | 0 | 20 | 20 | 20 | | | |
| | | | | Башлангыч әзерлекнең барлык этабында спорт әзерлеге узган һәм тренировкалар (спорт белгечлеге) этабына кертелгән затлар өлеше, % | 0 | 70 | 70 | 70 | | | |
| | | | | Муниципаль хезмәттән файдаланучыларның, ата-аналарның (законлы вәкилләрнең) нигезле шикаятьләре өлеше, % | 0 | 0 | 0 | 0 | | | |
| | | | | Муниципаль хезмәт сыйфатыннан һәм аннан файдалану мөмкинлегеннән канәгать булган муниципаль хезмәттән файдаланучылар, ата-аналар (законлы вәкилләр) өлеше, % | 0 | 80 | 80 | 80 | | | |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | Сәламәтлеккә зур зыян китергән тормыш иминлеге бозылу очраклары булу, берәмлек | 0 | 0 | 0 | 0 | | | |
| | | | | Ярышларда һәм башка шундый чараларда катнашучы муниципаль хезмәттән файдаланучылар саны, муниципаль хезмәттән файдаланучыларның гомуми санында (чаралар дәрәҗәсе суммасында) оешма, муниципаль, муниципальара, региональ, федераль, халыкара, % | 30 | 30 | 30 | 30 | | | |
| | | | | Программа материалларын үтәү, % | 100 | 100 | 100 | 100 | | | |
| | | | | Контингент сакланышы (федераль стандарт таләпләрен тулысынча үтәгән затлардан тыш, спорт белгечлегенең соңгы тренировка этабында, спорт осталыгын камилләштерү һәм югары спорт осталыгы этапларында һәм чыгарылыш сыйныф укучысы статусына ия этапларда), % | 70 | 70 | 70 | 70 | | | |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | Төркемнәрнең фактагы тулылыгының норматив тулылыкка нисбәте, % | 80 | 80 | 80 | 80 | | | |
| 11. | Муниципаль спорт мәктәпләренең хоккей спорт командаларының хоккей буенча Татарстан Республикасы чемпионатында һәм (яки) хоккей буенча Россия Федерациясе чемпионатында катнашуы | 1 муниципаль физик культура һәм спорт учреждениесе | 2023-2024 еллар | Муниципаль спорт мәктәпләренең хоккей спорт командалары катнашкан хоккей буенча Татарстан Республикасы чемпионаты һәм (яки) хоккей буенча Россия Федерациясе чемпионаты уеннары саны | 80 | 80 | | | Республика бюджеты | | |
| | | | | | | | | | 3401,8 | 1446,20 | |
| 12. | Спорт мәктәпләрен спорт инвентаре, җиһазлары, экипировкасы белән җиһазландыру | 16 муниципаль физик культура һәм спорт учреждениесе | 2023-2024 еллар | Спорт җиһазлары, экипировкасы һәм инвентаре сатып алуга субсидияләр алган, Яр Чаллы шәһәрендә спорт резервы әзерләүне гамәлгә ашыручы муниципаль учреждениеләр саны | 16 | | | | Республика бюджеты | | |
| | | | | | | | | | 2352,54 | 3111,21 | |

<table>
<tr><td rowspan="6">13.</td><td rowspan="6">Спорт әзерлеге оешмаларын норматив хәлгә китерү өчен спорт җиһазлары һәм инвентаре сатып алу чарасын тормышка ашыру</td><td rowspan="6">5 муниципаль физик культура һәм спорт учреждениесе</td><td rowspan="6">2023 ел</td><td rowspan="6">Спорт җиһазлары, экипировкасы һәм инвентаре сатып алуга субсидияләр алган, Яр Чаллы шәһәрендә спорт резервы әзерләүне гамәлгә ашыручы муниципаль учреждениеләр саны</td><td rowspan="6">7</td><td rowspan="6">5</td><td rowspan="6">5</td><td rowspan="6"></td><td colspan="3">Федераль бюджет</td></tr>
<tr><td>4063,15</td><td></td><td></td></tr>
<tr><td colspan="3">Республика бюджеты</td></tr>
<tr><td>953,08</td><td></td><td></td></tr>
<tr><td colspan="3">Муниципаль бюджет</td></tr>
<tr><td>50,67</td><td></td><td></td></tr>
<tr><td rowspan="4">14.</td><td rowspan="4">Татарстан Республикасы «Яр Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә физик культураны, массакүләм спортны үстерү, рәсми физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт чараларын үткәрүне оештыру өчен шартларны тәэмин итүгә бәйле чараларны тормышка ашыру</td><td rowspan="4">15 муниципаль физик культура һәм спорт учреждениесе</td><td rowspan="4">2023 ел</td><td rowspan="4">Рәсми физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт чараларында катнашуга субсидия алган, Яр Чаллы шәһәрендә спорт резервы әзерләүне гамәлгә ашыручы муниципаль учреждениеләр саны</td><td rowspan="4">15</td><td rowspan="4">15</td><td rowspan="4"></td><td rowspan="4"></td><td colspan="3">Республика бюджеты</td></tr>
<tr><td>3847,93</td><td></td><td></td></tr>
<tr><td colspan="3">Муниципаль бюджет</td></tr>
<tr><td>38,48</td><td></td><td></td></tr>
<tr><td rowspan="6">15.</td><td rowspan="6">Концессия килешүе нигезендә массакүләм спортның спорт инфраструктурасы объектларын булдыру (реконструкцияләү) буенча чараларны тормышка ашыру. Яр Чаллы шәһәрендә «ФИЗРА» спорт үзәге» физкультура-сәламәтләндерү</td><td rowspan="6">Башкарма комитетның физик культура һәм спорт идарәсе</td><td rowspan="6">2023 ел</td><td rowspan="6">Концессия килешүләре кысаларында булдырылган (реконструкцияләнгән) массакүләм спортның спорт инфраструктурасы объектлары саны, берәмлек</td><td rowspan="6"></td><td rowspan="6">1</td><td rowspan="6"></td><td rowspan="6"></td><td colspan="3">Федераль бюджет</td></tr>
<tr><td>54361,60</td><td></td><td></td></tr>
<tr><td colspan="3">Республика бюджеты</td></tr>
<tr><td>36241,07</td><td></td><td></td></tr>
<tr><td colspan="3">Муниципаль бюджет</td></tr>
<tr><td>915,17</td><td></td><td></td></tr>
</table>

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | комплексы» объектын булдыру, Яр Чаллы шәһәре, 40 лет Победы урамы, 52 микрорайон каршында, кадастр номеры: 16:52:070306:159 | | | | | | | | | | |

Башкарма комитет Аппараты Җитәкчесе
урынбасары, эш кәгазьләрен алып бару идарәсе
башлыгы вазыйфаларын башкаручы Л.Р. Абдуллина